**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2015 ел, 07 август

№ 572

г. Казань

2015 елда яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь төзәтү эшләрен башкару белән бәйле финанс ягыннан тәэмин итүгә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

2015 елда Татарстан Республикасы муниципаль районнарында яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь төзәтү чараларын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән 2015 елда яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь төзәтү эшләрен башкару белән бәйле финанс ягыннан тәэмин итүгә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренә субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\572.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 7 август, 572 нче
карары белән расланды

## 2015 елда яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь төзәтү эшләрен башкару белән бәйле финанс ягыннан тәэмин итүгә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренә субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип яшелчә продукциясен сыйфатлы саклауны тәэмин итү максатларында 2015 елда яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь төзәтү эшләрен башкару белән бәйле финанс ягыннан тәэмин итүгә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренә субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр бирү әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга «2015 елга һәм 2016 һәм 2017 елларның планлаштырылган чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына (алга таба – Министрлык) расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары кысаларында гамәлгә ашырыла.

3. Бетерелү стадиясендә булган яки түләргә хәле җитмәгән (банкрот) дип танылган авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренә субсидияләр бирелми.

4. Яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь төзәтү эшләрен башкару белән бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итүгә субсидияләр бирү өчен каралган акча белән төп эш йөртүче булып Министрлык тора.

Күрсәтелгән акча белән эш йөртүче булып «Татарстан Республикасының Баш инвестицион-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе тора.

5. Министрлык үзенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган шәхси счетыннан Татарстан Республикасының Баш инвестицион-төзелеш идарәсенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган шәхси счетына акча күчерүне гамәлгә ашыра.

6. Субсидияләр алу өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләре Татарстан Республикасының Баш инвестицион-төзелеш идарәсенә түбәндәге документларны тапшыралар:

үзләренең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү турында гаризаны;

авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләре тарафыннан таныкланган яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь төзәтүгә локаль смета исәпләре күчермәләрен;

яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь төзәтү эшләрен башкаруга подряд килешүләрен;

№ КС-2 статистик формасы буенча яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь төзәтү эшләрен кабул итү турында актны;

№ КС-3 статистик формасы буенча яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь төзәтү буенча башкарылган эшләр бәясе һәм чыгымнар турында белешмәне;

яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь төзәтү буенча яшерен эшләргә актлар белән башкарма документлар, кабул итү комиссиясе актын;

Министрлык белән килештереп, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы раслаган форма буенча субсидияләр бирү өчен белешмә-исәпләрне.

7. Баш инвестицион-төзелеш идарәсе:

субсидияләр бирү турында гаризаларны кергән көннәреннән соң бер көн эчендә терки;

гариза теркәлгән көннән соң 30 көн эчендә:

тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 6 пунктына туры килүен карап тикшерә, субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә, авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренә кабул ителгән карар турында хәбәр итә;

Министрлык белән килештереп, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы раслаган форма буенча авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүче яки кулланучылар кооперациясе предприятиесе белән субсидия бирү турында килешү төзи.

Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр булып түбәндәгеләр тора:

әлеге Тәртипнең 6 пунктында каралган документларның тулы комплекты бирелмәү;

авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүченең һәм кулланучылар кооперациясе предприятиесенең әлеге Тәртип шартларына туры килмәве.

8. Субсидия түләү турында уңай карар кабул ителгән очракта авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләре Татарстан Республикасының Баш инвестицион-төзелеш идарәсенә биргән белешмә-исәпләр нигезендә әлеге Тәртипнең 7 пунктындагы өченче абзацта күрсәтелгән вакыт узганнан соң биш көн эчендә Татарстан Республикасының Баш инвестицион-төзелеш идарәсе үзенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган шәхси исәбеннән авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренең исәп-хисап счетларына акча күчерә.

9. Субсидияләрне бирүнең әлеге Тәртиптә билгеләнгән максатларын һәм шартларын бозу, субсидияләрне максатчан билгеләнешендә файдаланмау һәм (яки) субсидияләр алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар бирү фактлары билгеле булганда Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән соң 60 көн эчендә бирелгән субсидияләр Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

10. Субсидияләр бирү турында килешүләрдә каралган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидия субсидияләр алучылар тарафыннан 2016 елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

11. Әлеге Тәртипнең 9 нчы һәм 10 нчы пунктларында күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджетына ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартылган очракта алар законнар нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

12. Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләре субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерүләрне гамәлгә ашыра.

13. Законнар нигезендә тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплылык авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләре җитәкчеләренә йөкләнә.

14. Бюджет акчасын максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны Министрлык гамәлгә ашыра.

---

F:\KARAR\2015\572-1.docx